**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**с. Тюлячи**

**КАРАР**

**«3» март 2022**

**№ 33**

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 9 декабрендәге 540 номерлы карары белән расланган «2021-2023 елларга Теләче муниципаль районы яшьләрен патриотик тәрбияләү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Район Башкарма комитетының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенең 2022 елның 09 мартындагы 46 номерлы хатын карап, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 16 сентябрендәге 666 номерлы «Татарстан Республикасы балаларын һәм яшьләрен патриотик тәрбияләү концепциясен раслау турында» карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019-2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 05 мартындагы 158 номерлы карары белән расланган «2019-2025 елларга Татарстан Республикасы яшьләрен патриотик тәрбияләү» ярдәмче программасы нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 9 декабрендәге 540 номерлы карары белән расланган «2021-2023 елларга Теләче муниципаль районы яшьләрен патриотик тәрбияләү» муниципаль программасына «2021-2023 елларга Теләче муниципаль районы яшьләрен патриотик тәрбияләү» программасы чаралары Исемлеген түбәндәге эчтәлекле 42 пункт белән тулыландырып, үзгәреш кертергә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 42 | Картинг буенча ярышларны оештырганда һәм катнашканда балалар һәм җиһазларны имин ташу өчен | ЯЭСhТБ | Берәмлекләр саны | РГДБ ААФИХЖ Теләче ЖО планы нигезендә Татарстан | РГДБ ААФИХЖ Теләче ЖО планы нигезендә Татарстан Респу | РГДБ ААФИХЖ Теләче ЖО планы нигезендә Татарстан Респуб | 2022-2023 еллар | Финанслау лимиты чикләрендә | Финанслау лимиты чикләрендә | Финанслау лимиты чикләрендә |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | транспорт чаралары түләүсез нигездә РГДБ ААФИХҖ Теләче ҖО тарафыннан бирү | | | Республикасы | бликасы | ликасы | | | | |

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин